РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Макаровского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

423568, Нижнекамский район,
с. Верхняя Уратьма ул. Молодежная, 2

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Макаровка авыл жирлеге
Советы

423568, Түбән Кама районы, Югары
Уратма авылы, Яшьлер урамы, 2

тел./факс (8555) 33-21-44, электронный адрес: sp.makarovskoe@tatar.ru,
сайт: www.makarovskoe-sp.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

13.09.2024ел № 11

«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2018 елның 23 июлендәге 14 номерлы Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Макаровка авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Макаровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Макаровка авыл җирлеге Советы хәл итә:

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2018 елның 23 июлендәге 14 номерлы Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Макаровка авыл җирлеге советы карарына (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 2 пункт өстәргә:

«4.1) 2025 елда - 1,2 процент, 2026 елда - 1,2 процент, 2027 елда - 1,2 процент, 2028 елда һәм аннан соңгы елларда гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан 2000 квадрат метрга кадәр булган административ-эшлекле үзәкләр һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) карата - 2 процент:

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән,

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган».

2 пунктның 1 пунктчасының 2 абзацында «мәйданы 30 квадрат метрдан артмаган һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә игълан итәргә.
3. 2 пунктның 4.2 пунктчасы 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

А.Н. Кудряшов

«СОВЕТ МАКАРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ»